ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 14.11.2023 **КАРАР**
1795

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1711 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының «Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 9 июлендәге 765 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 10 декабрендәге 1711 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту».

2. «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан

күмү урыннарын карап тоту» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) 2022-2026 елларга Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү буенча муниципаль программа чараларын үтәү өчен җирле бюджетта каралган ассигнованиеләр чикләрендә программаны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.11.2023   1795
номерлы карарына
1 нче кушымта

**«2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту» муниципаль программасы ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту» муниципаль программасы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның башкаручылары | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, гамәлдәге законнарда каралган, аукционнар үткәрү нигезендә җәлеп ителгән, төрле милек рәвешләрендәге сайлап алынган оешмалар |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максатлары булып түбәндәгеләр тора:<br>-Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, шәһәр халкының яшәү сыйфатын яхшырту һәм уңайлы мохит тудыру.<br>Программаның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:<br>- зират территорияләрен киңәйтү;<br>- зират һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2022-2026 еллар. |
| Программаны финанслауда ихтыяҗ күләме | Программаны 2022-2026 еллар чорында финанслау күләме - 8 500,0 мең сум,<br>шул исәптән:<br>○ 2022 елда - 1 700,0 мең сум, шулардан: |

| | |
|---|---|
| | жирле бюджет акчалары - 1 700,0 мең сум,<br>o 2023 елда - 1 700,0 мең сум, шулардан: жирле бюджет акчалары - 1 700,0 мең сум,<br>o 2024 елда - 1 700,0 мең сум, шулардан: жирле бюджет акчалары - 1 700,0 мең сум.<br>o 2025 елда - 1 700,0 мең сум, шулардан: жирле бюджет акчалары - 1 700,0 мең сум,<br>o 2026 елда - 1 700,0 мең сум, шулардан: жирле бюджет акчалары - 1 700,0 мең сум |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру шәһәр халкының зиратка барып, каберлекләрне һәм аның янындагы территорияләрне норматив хәлдә карап тотуны тәэмин итү өчен уңайлы шартлар тудыруга юнәлтелгән. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру | Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла. |

## 1. Муниципаль программаны тормышка ашыру сферасының характеристикасы

2021 елның 1 гыйнварына Алабуга шәһәре халкының саны - 70 799 кеше тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тоту заманча таләпләргә җавап биреп бетерми. Күмү урыннарын төзекләндерүдә мәсьәләләрендә кайбер проблемалар бар.

Төзекләндерү һәм санитар таләпкә туры китереп тоту зур кыенлыклар китереп чыгара. Каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны җыю һәм чыгару, яктырту җиһазлары җитди кыенлыклар тудыра. Әлегә җирләү урыннары булган территорияләр янындагы урамнар яктыртылмый, яктырту өчен өстәмә финанслау таләп ителә.

Әлеге проблеманы хәл итү өчен Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре җирле үзидарә органнарын, предприятиеләрне һәм оешмаларны җәлеп итеп, халыкның, предприятиеләрнең һәм оешмаларның, барлык дәрәҗәдәге бюджетлар чыганакларын җәлеп итеп, финанслауның булуы белән үзара хезмәттәшлеге һәм аларның катнашуы да таләп итә.

Муниципаль берәмлектә җирләү урыннарын карап тоту проблемаларын хәл итү өчен Алабуга шәһәре максатчан программа методын кулланырга тиеш. Югарыда күрсәтелгән проблемаларны комплекслы хәл итү җирләү урыннарының санитар-эпидемиологик торышына, гражданнарның тормышына һәм иминлегенә уңай тәэсир итәчәк, җирләүдә хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итәчәк.

Төзекләндерүне яхшырту мәсьәләләре буенча эшләрне планлаштыруга һәм оештыруга, Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарының санитар торышына, җирләү өчен уңайлы шартлар тудыруга, финанс һәм оештыру ресурсларын мобилизацияләү буенча конкрет эшчәнлек әлеге программа нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

## 2. Программаның максатлары, бурычлары

Программаның төп максатлары түбәндәгеләр:

- Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү, шәһәр халкының яшәү өчен уңайлы шарт һәм уңайлы мохит тудыру.

Программаның төп бурычлары:

- зират территорияләрен киңәйтү;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- зират һәм аның тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

2026 елга әлеге программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр тәэмин ителәчәк:

1) зиратларны сыйфатсыз карап тоту мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгате санын киметү;
2) күмү урыннары территориясендә киртәләр урнаштыру;
3) күмү урыннары территориясенә килү юлларын норматив хәлгә китерү;
4) инвентарьны саклау өчен хуҗалык корылмалары төзү;
5) контейнер мәйданчыклары төзү һәм урналар урнаштыру;

Программа 2022 - 2026 еллар дәвамында гамәлгә ашырыла.

Һәр чараны гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар (финанслау чыганаклары киселешендә) турындагы мәгълүматны күрсәтеп, чаралар исемлеге, программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары әлеге программаның 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

**Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү**

Программа муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан күмү урыннарында тиешле шартларны булдыруга юнәлдерелгән чараларны әзерләү һәм гамәлгә ашыру тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнгән.

Программа гражданнарны җирләү урыннарны карап тоту өчен тиешле шартлар тудыруга, идарә системасын камилләштерүгә, исәпкә алуның электрон системаларын гамәлгә кертүгә, хуҗалык эшчәнлегеен оператив алып баруга һәм Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан күмү урыннары экологик иминлекне арттыруга юнәлдерелгән.

Программаның төп юнәлешләре булып җирләү урыннарын, су ресурсларын саклау һәм карап тотуны, җирләү һәм табигый-экологик балансны саклауны урыннарында халык эшчәнлеге калдыкларын утильләштерү чараларын күздә тота.

Программаны финанслау күләме - 5 100,0 мең сум, шул исәптән:
- җирле бюджет акчалары - 2022 ел - 1 700,0 мең сум;
- җирле бюджет акчалары – 2023 ел - 1 700,0 мең сум;
- җирле бюджет акчалары – 2024 ел - 1 700,0 мең сум;
- җирле бюджет акчалары – 2025 ел - 1 700,0 мең сум;
- җирле бюджет акчалары – 2026 ел - 1 700,0 мең сум.

Программа Алабуга шәһәренең чыгымының йөкләмәсе булып тора. Программаны үтәү җирле бюджет акчалары исәбеннән башкарыла.

Программаны финанслау күләмнәре, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле финанс елына расланган Алабуга шәһәре бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, аны гамәлгә ашыру барышында төзәтелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарының исемлеге әлеге программаның 2 нче кушымтада бирелгән.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру белән идарә итүне муниципаль программа заказчысы - Татарстан Республикасы Алабуга шәһәре Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

Программаның заказчысы Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы, Программа чараларын гамәлгә ашыру срокларын һәм аларны финанслау күләмнәрен аныклый.

Программаның заказчысы түбәндәге төп бурычларны үти:

- программа проектларының һәм программа чараларының нәтиҗәлелегенә икътисади анализ;
- чираттагы чорга инвестиция һәм агымдагы чыгымнар планын төзү буенча тәкъдимнәр әзерләү;
- республика һәм җирле бюджетларны кабул итү нәтиҗәләре буенча программаны гамәлгә ашыру планына һәм финанслау чыганаклары һәм күләмнәре буенча һәм Программаны тормышка ашыруга тәкъдим ителә торган бурычлар исемлегеннән чыгып төзәтмәләр кертү һәм башка чыганаклардан финанслауның ихтимал күләмнәрен ачыклау;
- Программа күрсәткечләрен үтәү һәм оператив хисап мәгълүматын җыю, программаны тормышка ашыруның барышы турында билгеләнгән тәртиптә хисап әзерләү һәм тапшыру мониторингы.

Программаның чаралары Программа заказчысы һәм төрле милек рәвешләрендәге оешмалар арасында аукционнар уздыру нигезендә гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә сайлап алынган муниципаль контрактлар төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыруны тикшереп тору Татарстан Республикасы Алабуга шәһәренең Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 5. Муниципаль программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашырудан социаль-икътисадый эффект (нәтиҗә) Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын карап тотуның сыйфатын яхшыртуда, территорияләрне санитар карап тотуда, җирләү урыннарының экологик иминлеген тәэмин

итүдә, зиратлар территорияләрендә авырулар, корыган, черек агачлар санын киметүдә чагыла.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннарын төзекләндерү көтелә.

Билгеләнгән әлеге чараларны үтәү гражданнарның канәгатьлелеген Алабуга шәһәре зират территорияләрен карап тотуның дәрәҗәсен арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

2022-2024 елларга
Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Алабуга шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә урнашкан
күмү урыннарын карап тоту
муниципаль программасына
1 нче кушымта

## Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Төп чараланыңр аталышы | Башкару чылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | Бюджет хисабына финанслау (мең сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025ел | 2026 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Максат: Алабуга шәһәре территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру, шәһәр халкының яшәү өчен уңайлы мохит тудыру | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: зиратларны һәм аның янындагы территорияләрне төзекләндерү | | | | | | | | | | | | | |
| Чүп контейнерлары өчен мәйданчыклар төзү һәм чүп савытлары урнаштыру | БК | 2022-2026 | данә | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 | 150,0 |
| Зират территорияләреннән чүп җыю һәм чыгару | БК | 2022-2026 | кв.м. | 265,7 | 265,7 | 265,7 | 265,7 | 265,7 | 290,5 | 290,5 | 290,5 | 290,5 | 290,5 |
| Шәһәр чүплегендә шәһәр зиратларында урнаштырылган контейнерлардан чүп-чар чыгару һәм урнаштыру | БК | 2022-2026 | тонна | 144 | 144 | 144 | 144 | 144 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 |
| Бурыч: Зират территорияләрен киңәйтү | | | | | | | | | | | | | |
| Күмү урыннары территориясендә коймалар урнаштыру | БК | 2022-2026 | кв.м | 300 | 200 | 200 | 200 | 200 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 | 1000,0 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Күмү урыннары территориясенә керү юлларын норматив хәлгә китерү | БК | 2022-2026 | кв.м | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | 158,0 | 158,0 | 158,0 | 158,0 | 158,0 |

2022-2026 елларга
Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Алабуга шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә урнашкан
күмү урыннарын карап тоту
муниципаль программасына
2 нче кушымта

**2022 – 2026 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан күмү урыннары исемлеге**

| **№ т/б** | **Зират** | **мәйданы, кв. м.** |
|---|---|---|
| 1 | 1 нче санлы рус зираты | 34 077,6 |
| 2 | 2 нче санлы рус зираты | 5 525,2 |
| 3 | 3 нче санлы рус зираты | 36 597,3 |
| 4 | 4 нче санлы рус зираты | 26 016,5 |
| 5 | 5 нче санлы рус зираты | 22 467,8 |
| 6 | Иске татар зираты | 21 596,5 |
| 7 | Японнар зираты | 4 194,1 |
| 8 | Алманнар зираты | 3 182,7 |
| 9 | Яңа Татар зираты | 24 110,0 |
| 10 | Яңа Рус зираты | 36 936,0 |
| 11 | Троицкий зираты | 5 863,7 |
| 12 | Тарлау авылы зираты | 21 000 |
| 13 | Яңа Татар зираты 2 | 24 110,0 |
|  | **БАРЫСЫ:** | **265 677,4** |

Лист согласования к документу № 1795 от 14.11.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 11.12.2023 13:22

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>11.12.2023 - 15:17 | - |